Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Кубас авыл җирлеге Советы
Карары

2019 елның 27 нче ноябре № 73/1

Чистай муниципаль районы
Кубас авыл җирлеге Советының
2016 елның 10 ноябрендәге 23 номерлы
«Җир салымын түләү ставкасын,
тәртибен һәм срокларын билгеләүне гамәлгә кертү турында»гы
Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексына кертелгән үзгәрешләр нигезендә, Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 ноябрендә кабул ителгән 23 номерлы «Җир салымын түләү ставкасын, тәртибен һәм срокларын билгеләүне гамәлгә кертү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 1 пунктның 1.1 пунктчасындагы 3 абзацында «(физик, юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә)» сүзләрен «(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга»;

1.2. 3 пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләрен, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата - 0,2 процент күләмендә.»;

1.3. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Салым түләүчеләр - салым ташламаларына хокуклы физик затлар, шул исәптән салым салынмый торган суммага салым базасын киметү рәвешендә салым органына үз теләкләре белән салым ташламасы бирү турында гариза тапшырырга, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тәкъдим итәргә хокуклы.».

2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма әлеге карарның рәсми басылып чыккан көненнән соң кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

Кубас авыл җирлеге
башлыгы Н. С. Логинова